ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**08.02.2023** **Чистай шәһәре** **№ 59**

Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны күмү (җирләү) чараларын оештыру чыгымнары турында

Татарстан Республикасының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә һәлак булган ватандашлар турында хәтерне саклап калу максатларында Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсонск өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарны күмүне (җирләүне) оештыру максатларында, «Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе кораллы көчләрен файдалану турында»гы 2022 елның 22 февралендәге 35-СФ номерлы Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы карары белән, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»гы Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы белән, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенә, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы “Күмү һәм җирләү эше турында”гы Федераль законына нигезләнеп, аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарны җирле бюджет акчалары исәбеннән күмүне (җирлшүне) оештыруны тәэмин итәргә.
2. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарны күмүне (җирләүне) оештыру чыгымнарын финанслау тәртибен расларга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының

рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитета
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 8 февралендәге
59 номерлы карарына Кушымта

**«Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарны күмүне (җирләүне) оештыру чыгымнарын финанслау**
**Тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә һәлак булган ватандашлар турында хәтерне саклап калу максатларында, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсонск өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарны күмүне (җирләүне) оештыру максатларында, «Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе коралль көчләрен файдалану турында»гы 2022 елның 22 февралендәге 35-СФ номерлы Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы карары белән, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»гы Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы белән, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенә, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы “Күмү һәм җирләү эше турында”гы Федераль законына нигезләнеп, аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен эшләнде.

Әлеге Тәртипне гамәлгә ашыру максатларында, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнар дигәндә, махсус хәрби операциядә катнашкан һәм һәлак булган (алга таба - һәлак булганнар), шулай ук хәрби хәрәкәтләр барышында алынган яралар нәтиҗәсендә госпитальләрдә һәм медицина учреждениеләрендә вафат булган гражданнар күздә тотыла.

II. Чыгымнарны финанслау тәртибе

Күмүне (җирләүне) (алга таба текст буенча - җирләү) оештыруга чыгымнар Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Чистай шәһәре, Чистай һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары хәрби комиссарының хәбәр язуына (хатына) таянып төзелгән чыгымнар сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җирләүне турыдан-туры оештыру төзелгән шартнамәләр нигезендә җирләү бурычларын үтәү өчен җаваплылыкны үз өстенә алган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Һәлак булган кешенең туганнары аны башка муниципаль район территориясендә җирләргә теләк белдергән очракта, Чистай муниципаль районы җирләүне оештыру чыгымнарын күрсәтми.

Күрсәтелгән чыгымнар өчен түләү аларны гамәлгә ашыруны раслаучы документлар (шартнамәләр, счет-фактуралар, түләүгә счетлар, күрсәтелгән хезмәтләрне (башкарылган эшләрне) кабул итү-тапшыру актлары) һәм Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәлак булган кешене җирләүне оештыру чыгымнары сметасы булган очракта башкарыла, ул

транспорт хезмәтләрен, җирләү көнендә искә алу ашын, чәчәкләр, веноклар, тасмалар, сөлгеләр сатып алуны, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны (газета, социаль челтәр), кайгы уртаклашу, ритуаль хезмәтләр (мәетне моргка китерү, морг хезмәтләре, табутны бирү һәм китерү, тәре, кабер казу, йөк ташучылар хезмәте, мәетне (мәет калдыкларын) күчерү, туганнарны күмү урынына китерү) үз эченә ала.

Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан бюджет ассигнованиеләрен һәм финанслауның иң чик күләмнәрен җирле бюджет акчалары алучы буларак Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен әлеге Тәртиптә каралган максатларга туры килә торган сумма чикләрендә җирле бюджет акчалары исәбенә гамәлгә ашырыла.

Әгәр җирләү дәүләт хакимияте органнары тарафыннан башкарылса, җирләүне оештыру һәм күмү чыгымнары башкарылмый.

Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп тора.